**СОВЕТ ЧИРПОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422615, с. Чирпы,
ул. Молодежная, д.4а
тел: 2-91-45

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЧИРПЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**
422615, Чирпы авылы,
Яшьләр урамы, 4а нчы йорт,
тел: 2-91-45

2019 елның 5 декабре 23 номер

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чырпы авыл җирлеге составына керүче Имәнкискә торак пунктындагы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 19 ноябрендә булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге- «2020 елда, яшәү урыны буенча, Лаеш муниципаль районы Чырпы авыл җирлеге составына керүче Имәнкискә торак пункты территориясендә теркәлгән балигъ яшьтәге һәр кешедән, бала чактан инвалид булганнардан һәм көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм,түбәндәге эшләрне башкару буенча, алынган акчаларны җирле мәсьәләләрне:

- Чырпы авыл җирлеге составына керүче Имәнкискә торак пункты урам-юл челтәрен төзү, ремонтлау һәм карап тотуны хәл итүгә юнәлтергә килешәсезме?”-дигән сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучылар исемлегенә, сайлау хокукына ия булган, 518 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнарның саны 378 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында 378 катнашучы «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

"Юк" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чырпы авыл җирлеге составына керүче Имәнкискә торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип таныргa.
2«2020 елда, яшәү урыны буенча, Лаеш муниципаль районы Чырпы авыл җирлеге составына керүче Имәнкискә торак пункты территориясендә теркәлгән балигъ яшьтәге һәр кешедән, бала чактан инвалид булганнардан һәм көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм,түбәндәге эшләрне башкару буенча, алынган акчаларны җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Чырпы авыл җирлеге составына керүче Имәнкискә торак пунктын урам-юл челтәрен төзү, ремонтлау һәм карап тотуны хәл итүгә юнәлтергә килешәсезме?»-соравы буенча карарны кабул ителгән дип таныргa

3. Әлеге карарны Чырпы авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, http:// pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында игълан итәргә: һәм http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

4 Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Чырпы авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: _________________ Р.А.Евдокимов

Чырпы авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе _________________ Р.А.Евдокимов